**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.11.2023 № 534-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 28 февралендәге 133-осн номерлы боерыгы белән расланган Бөгелмә урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 83 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлешендәге 1 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Бөгелмә урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында» 2019 елның 28 февралендәге 133-осн номерлы боерыгы (02.03.2020 № 177-осн, 01.12.2020 № 810-осн, 13.01.2022 № 12-осн боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Әлмәт урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары И.Н.Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгының
2019 елның 28 февралендәге 133-осн
номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының 2023
елның 27 ноябрендәге 534-осн
номерлы боерыгы редакциясендә)

# БӨГЕЛМӘ УРМАНЧЫЛЫГЫНЫҢ
# УРМАН ХУҖАЛЫГЫ РЕГЛАМЕНТЫ

(2023 елның 1 гыйнварына булган торышында)

**Казан шәһәре – 2023**

Эчтәлек

КЕРЕШ ........ 6
1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР ........ 18
1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама ........ 18
1.1.1. Урманчылык һәм урнашкан урыны ........ 18
1.1.2. Урманчылыкның, кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы, урманчылык территориясенең районнар буенча бүленеше ........ 18
1.1.3. Урман үсә торган зоналар, урманлы районнар һәм урманнарны саклау һәм урман-орлык районнарына бүлү зоналары буенча урманчылык урманнарын бүлү ........ 21
1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм саклагыч урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук саклагыч, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре ........ 23
1.1.5. Урманчылык территориясендә урман фонды җирләре составыннан урманлы һәм урмансыз җирләргә сыйфатлама ........ 26
1.1.6. Гамәлдәге һәм проектлана торган махсус саклана торган табигать территорияләренә һәм объектларга, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелеген саклау планнарына сыйфатлама ........ 26
1.1.7. Илкүләм мирас буенча проектлана торган урманнарга сыйфатлама ........ 32
1.1.8. Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек төрләрен һәм буфер зоналары зурлыклары исемлеге ........ 32
1.1.9. Гамәлдәге урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларына, урман инфраструктурасы ясауга бәйле булмаган объектларга, әлеге объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү чараларына территориаль планлаштыру документларында каралган сыйфатлама ........ 37
1.2. Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре ........ 40
2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ЧОРЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮРЧЕТҮ НОРМАТИВЛАРЫ ........ 45
2.1. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 45
2.1.1. Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү буенча файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме ........ 46
2.1.2. Урманнарны тәрбияләгәндә урта яшьле, өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү буенча файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме (агач материалы алуның ел саен рөхсәт ителгән күләме) ........ 80
2.1.3. Барлык төр кисүләрдә файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме (агач материалы алуның ел саен рөхсәт ителгән күләме) ........ 127
2.1.4. Кисентеләрнең яше ........ 130
2.1.5. Агачлыкларның тулылыгын һәм составын, диләнкеләрнең күләмнәрен, диләнкеләрнең тоташу чорларын, киртекләр санын, кисүләрнең кабатлану чорларын исәпкә алып, агач материалын сайлау проценты (ешлыгы) ........ 131
2.1.6. Урманнарны торгызу алымнары ........ 134
2.1.7. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен файдалану вакытлары һәм башка мәгълүматлар ........ 134

2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........................................................................................... 135
2.3. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары........................................... 137
2.3.1. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары ............................................................................................................ 138
2.3.2. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю өчен файдалану чорлары ............................................................................................... 138
2.4. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары .................................. 138
2.4.1. Урманнардан азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары ........................................................................... 139
2.4.2. Әзерләү һәм җыеп алу вакытлары ................................................................... 140
2.4.3. Агач сутлары әзерләгәндә нормативлар һәм параметрлар ............................ 140
2.4.4. Абага-кара абага әзерләү .................................................................................. 141
2.4.5. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану чорлары ................................................................................... 141
2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары .................................. 141
2.5.1. Аучылык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен рөхсәт ителгән биотехник чаралар уздыру исемлеге һәм нормалары ............................................. 142
2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........................................................................................... 143
2.6.1. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары...... 143
2.7. Балыкчылыкны гамәлгә ашыру, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш................ 144
2.8. Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары....................... 144
2.9. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ................................................................ 145
2.9.1. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары ................................................................................................................ 145
2.9.2. Рекреация эшчәнлеге зонасына караган, шул исәптән физик-культура, спорт һәм спорт-техник корылмалар торгызу рөхсәт ителә торган, кварталларның һәм (яисә) аларның өлешләренең исемлеге. ..................................................................... 145
2.9.3. Рекреация эшчәнлегенә караган зона территориясен функциональ зоналарга бүлү ................................................................................................................................ 145
2.9.4. Урман кишәрлекләрендә вакытлыча төзелгән корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары ........................................................................... 146
2.9.5. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану параметрлары һәм чорлары ........................................................................................... 146
2.10. Урманнардан урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары............................................ 147

2.11. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен һәм дару үләннәрен үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары...... 147
2.12. Урманнардан урман питомниклары ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары.......................................... 148
2.13. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ...................................................................................... 149
2.14. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары булдыру һәм аларны киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары.......................................... 150
2.15. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары.......................................... 151
2.16. Урманнардан урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары....... 155
2.17. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ...................................................................................... 156
2.18. Урманнарны саклауга һәм яңадан үрчетүгә карата таләпләр ......................... 156
2.18.1. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм тискәре башка йогынтыдан саклауга карата таләпләр ........................................................................................................................ 156
2.18.2. Урманнарны саклауга карата таләпләр (санитар-савыктыру чараларының, урманнарны саклау буенча профилактика чараларының, зарарлы организмнарның чыганакларын ликвидацияләү чараларының, шулай ук вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән башка чараларның нормативлары һәм параметрлары) ..................................................................................................................................... 160
2.18.3. Урманнарны яңадан үрчетүгә карата таләпләр (урманнарны торгызу, урман үстерү, урманнарны карау чараларын үткәрү нормативлары, параметрлары, чорлары) ......................................................................................................................... 168
2.19. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре............................................................................ 182
3 БҮЛЕК. Урманнардан файдалануда чикләүләр .................................................. 183
3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләүләр .................... 183
3.2. Махсус саклана торган урман кишәрлекләренең төрләре буенча чикләүләр.... 185
3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр ......................................... 187

## КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты Бөгелмә урманчылыгы чикләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау һәм торгызу нигезе булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 7 өлеше, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу срокларын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерыгы нигезендә әзерләнде.

Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу чоры – 2029 елның 1 апреленә кадәр.

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә дәүләт урман реестры материаллары файдаланылды.

Регламентны эшләүчеләр:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

Почта адресы: Ямашев проспекты, 37А йорт, Казан шәһәре, 420124.

E-mail: Minleshoz@tatar.ru.

Сайт: Minleshoz.tatarstan.ru.

Тел. (843) 221-37-01.

Факс (843) 221-37-37.

## Россия Федерациясенең закон актлары

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ Урман кодексы).

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ Су кодексы).

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы).

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы).

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Янгын куркынычсызлыгы турында» ФЗ).

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы федераль закон).

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон).

«Геодезия, картография һәм киңлек мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 431-ФЗ номерлы федераль закон).

«Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында» 1997 елның 19 июлендәге 109-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы федераль закон).

«Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы федераль закон).

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы федераль закон).

«Җир корылышы турында» 2001 елның 18 июнендәге 78-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы федераль закон).

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы федераль закон).

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы федераль закон).

«Элемтә турында» 2003 елның 07 июлендәге 126-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 04 декабрендәге 201-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы федераль закон).

«Орлыкчылык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 454-ФЗ номерлы федераль закон).

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон).

«Үсемлекләр карантины турында» 2014 елның 21 июлендәге 206-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 206-ФЗ номерлы федераль закон).

«Җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 172-ФЗ номерлы федераль закон).

## РФ Урман кодексында каралган хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар (2023 елның 01 гыйнварына)

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 91 статьяның 7 өлеше | Дәүләт реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү күләме һәм аны алу тәртибе турында» 2007 елның 3 мартындагы 138 номерлы карары |
| 100 статья | Урманнарга һәм алардагы табигать объектларына | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга һәм |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | китерелгән зыянны каплау | аларда булган табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары |
| 96 статья | Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) турында» 2021 елның 30 июнендәге 1098 номерлы карары |
| 50 статьяның 3 өлеше | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының максималь күләмен билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының иң зур күләмен билгеләү турында» 2007 елның 22 июнендәге 395 номерлы карары |
| 73 статьяның 4 өлеше | Федераль мөлкәттәге урман ресурслары бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеген арендалау өчен урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген түләүле нигездә файдалануга алу буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| 44 статья | Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су объектын файдалануга бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 18 номерлы карары |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә чыбыкларын һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары |
| 76 статьяның 3 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре буенча түләү. Федераль мөлкәттә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтендә һәм муниципаль мөлкәттә торучы җирләрдә әзерләнә торган агач материалы берәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген түләүле нигездә файдалануга алу буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| $23^1$ статьяның 3 өлеше, $60^3$ статья | Урманнарда санитар куркынычсызлык. Урман утыртмаларын кисү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда санитария куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | тәртибе | декабрендәге 2047 номерлы карары |
| 23[1] статьяның 3 өлеше, 53 статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 7 октябрендәге 1614 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны янгына каршы кору чаралары турында» 2011 елның 16 апрелендәге 281 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 1464 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында» 2011 елның 17 маендагы 376 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннарын сүндерү планын төзү һәм аны һәм аның рәвешен раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 17 маендагы 377 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 18 августындагы 687 номерлы карары |
| 22 статьяның 3 өлеше | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция эшчәнлеге.<br>Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны үзләштерү турында өстенлекле инвестиция проектлары турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 23 февралендәге 190 номерлы карары |
| 114 статьяның 6 өлеше | Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарның функциональ зоналары | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән урманнар булган җирләрнең чикләрен үзгәртү һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда функциональ зоналарны билгеләү ғагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 21 декабрендәге 1755 номерлы карары |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 13 статья | Урман инфраструктурасы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, файдаланыла торган урманнар һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге 1283-р номерлы күрсәтмәсе |
| 21 статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар исемлеген раслау турында» 2022 елның 30 апрелендәге 1084-р номерлы күрсәтмәсе |
| $21^1$ статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары, резерв урманнары өчен урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү» 2022 елның 23 апрелендәге 999-р номерлы күрсәтмәсе |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары |
| $73^1$ статьяның 6 өлеше | Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү<br>Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агач материалы әзерләү өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста катнашучыларның конкурс тәкъдимнәрен бәяләү кагыйдәләрен һәм тәкъдим ителгән шартларны бәяләү һәм агач материалы әзерләү өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль  милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста җиңүчене билгеләүгә нигез булган билгеләрне раслау турында» 2019 елның 7 мартындагы 241 номерлы карары |
| **Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгы) норматив актлары** | | |
| 62 статьяның 7 өлеше | Урман торгызу. Урман торгызу кагыйдәләре | «Урманнарны торгызу кагыйдәләрен, урманнарны торгызу проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урманнарны торгызу проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1024 номерлы боерык |
| $73^{1}$ статьясындагы 7 өлеше | Урман кишәрлегенең типик аренда шартнамәсе | «Урман кишәрлекләрен түләүле нигездә файдалануга тапшыруның бер төрле шартнамәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 542 номерлы боерык |
| 77 статьяның 7 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу турында типик шартнамә | «Урман утыртмаларын сату-алуның бер төрле шартнамәсен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 488 номерлы боерык |
| $60^{15}$ статья | Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләре | «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 29 маендагы 264 номерлы боерык |
| $23^{1}$ статьяның 3 өлеше, 64 статьяның 3 өлеше | Урманнарны тәрбия кылу. Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Урманнарны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 534 номерлы боерык |
| 112 статьяның 5 өлеше | Махсус сакланучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләре | «Махсус саклана торган табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләрен раслау турында» 2021 елның 12 августындагы 558 номерлы боерык |
| $53^{1}$ статья | Урман янгыннарын кисәтү | «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативларын, урманнардан файдаланганда булырга тиешле урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары нормаларын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 161 номерлы боерык |
| $53^{1}$ статья | Урманнарда янгын чыгу куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау | «Урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын күзәтүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 июнендәге 276 номерлы боерык |
| 15 статьяның 3 өлеше | Урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар | «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерык |
| 87 статьяның 7 өлеше | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның | «Урман хуҗалыгы регламентлары составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | гамәлдә булу вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерык |
| $60^{5}$ статья | Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы | «Урман авырулары буенча дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 апрелендәге 156 номерлы боерык |
| $60^{7}$ статья | Зарарлы организмнар таралуны кисәтү | «Зарарлы организмнар таралуны кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 912 номерлы боерык |
| $60^{6}$ статьяның 4 өлеше | Урман патологиясе буенча тикшеренүләр. Урман патологиясе буенча тикшеренүләрне уздыру тәртибе | «Урман авыруларына бәйле тикшеренүләрне уздыру тәртибен һәм урман авыруларына бәйле тикшеренү актының рәвешен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 910 номерлы боерык |
| $23^{2}$ статьяның 10 өлеше, 29 статьяның 11 өлеше, $23^{1}$ статьяның 3 өлеше | Диләнке эшләре.<br>Агач материалы әзерләү.<br>Агач материалы әзерләү кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерык<br>«Диләнке эшләре төрләрен, аларны башкару тәртибен һәм эзлеклелеген, диләнке эшләренең технологик картасы формасын, урман бүлемтеген актыкка тикшерү акты формасын һәм урман бүлемтеген актыкка карап чыгу тәртибен раслау турында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 23 номерлы боерык,<br>«Урман бүлемтегенең таксация тасвирламасына кертелә торган мәгълүматлар составын, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасын төзү тәртибен, аның электрон форматындагы форматына карата таләпләрне, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасының урман бүлемтегенең хакыйкый торышы турындагы мәгълүматка туры килмәвен билгеләү тәртибен, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасы формасын раслау турында» 2022 елның 14 октябрендәге 687 номерлы боерык |
| $60^{4}$ статья | Урманнарны яклау буенча районнарга бүленеш | «Урманнарда җиңелчә, уртача һәм көчле урман патологиясе булган зоналарны билгеләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерык |
| 91 статья | Дәүләт урман реестры | «Дәүләт урман реестрына документлаштырылган мәгълүматлар кертүгә |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | һәм аны үзгәртүгә нигез булган документларның исемлеген, аларның формаларын һәм аларны әзерләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 ноябрендәге 496 номерлы боерык,<br>«Дәүләт урман реестрында булган, зарури тәртиптә бирелә торган мәгълүматлар төрләре исемлеген һәм аны бирү шартларын раслау турында» 2013 елның 30 октябрендәге 464 номерлы боерык,<br>«Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 1007 номерлы боерык |
| $70^{1}$ статьяның 12 өлеше | Урман кишәрлекләрен проектлау | «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында» 2017 елның 3 февралендәге 54 номерлы боерык |
| $60^{13}$ статья | Урманнарны радиоактив пычранудан саклау үзенчәлекләре | «Урманнарның радиоактив пычрану зоналарында профилактика һәм тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 8 июнендәге 283 номерлы боерык |
| 65 статьяның 5 өлеше | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкчылыгы объектларын (урман орлыкчылыгы плантацияләрен, даими урман орлыклары кишәрлекләрен) төзү һәм аерып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 438 номерлы боерык,<br>«Урманның төп агач токымнарының үстерү районнарына бүленгән урман үсемлекләре орлыкларын куллану тәртибен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 909 номерлы боерык |
| 46 статьяның 4 өлеше | Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | «Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерык |
| 38 статья | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану | «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерык |
| 49 статьяның 4 өлеше | Урманнардан файдалану турында хисап.<br>Урманнардан файдалану | «Урманнардан файдалану турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнардан файдалану турында хисап |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | турында хисап тапшыру тәртибе | тапшыру формасын һәм тәртибен, шулай ук урманнардан файдалану турында электрон рәвештә хисап формасына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 451 номерлы боерык |
| 66 статьяның 2 өлеше | Урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисап. Урманнардан файдалану һәм урман үстерү турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында электрон рәвештәге хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 452 номерлы боерык |
| 89 статья | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза. Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибе | «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы һәм муниципаль экспертиза тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 513 номерлы боерык |
| 26 статьяның 3 өлеше | Урман декларациясе. Урман декларациясен тутыру һәм тапшыру тәртибе | «Урман декларациясе формасын, аны тутыру һәм тапшыру тәртибен, электрон рәвештә урман декларациясе форматына таләпләр раслау турында» 2021 елның 29 апрелендәге 303 номерлы боерык |
| 60 статьяның 3 өлеше, $60^{11}$ статьяның 3 өлеше | Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап. Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап тапшыру тәртибе. | «Урманнарны янгыннардан саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны янгыннардан саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны янгыннардан саклау турында электрон рәвештә хисап тапшыру форматына карата таләпләр, урманнарны яклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яклау турында электрон рәвештә хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 09 мартындагы 78 номерлы боерык |
| $60^{8}$ статьяның 5 өлеше | Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү | «Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 913 номерлы боерык |
| $53^{4}$ статья | Урман янгыннарын сүндерү | «Урман янгыннарын сүндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 1 апрелендәге 244 номерлы боерык |
| $98^{2}$ статья | Урман сагы | «Урман сагын гамәлгә ашыру тәртибен һәм |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | нормативларын раслау турында» 2021 елның 15 декабрендәге 955 номерлы боерык |
| $64^1$ статьяның 2 өлеше | Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү тәртибен һәм тиешле акт рәвешләрен раслау турында» 2019 елның 11 мартындагы 150 номерлы боерыгы |
| 86 статьяның 5 өлеше | Россия Федерациясе субъектының урман планы. Россия Федерациясе субъектының урман планы составы һәм аны әзерләү тәртибе | «Россия Федерациясе субъекты урман планының бер төрле рәвешен һәм составын, аны әзерләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 692 номерлы боерык |
| 32 статья | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы боерык |
| 67 статья, 68 статья | Урман корылышы турында гомуми нигезләмәләр Урман корылышының эчтәлеге | «Урман корылышы буенча файдалану күрсәтмәсен раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 510 номерлы боерык |
| 63 статьяның 3 өлеше | Урман үстерү. Урман үстерү кагыйдәләре | «Урман үстерү кагыйдәләрен, урман үстерү проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урман үстерү проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы боерык |
| 88 статьяның 2 өлеше | Урманнарны үзләштерү проекты. | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарны үзләштерү проектының составын, аны эшләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен, электрон документ рәвешендә урманнарны үзләштерү проекты форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 864 номерлы боерыгы |
| $39^1$ статья | Урман питомникларын булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | «Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерык |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | «Урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урман кишәрлеген бирмичә урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | июлендәге 434 номерлы боерык |
| 43 статья | Җир астын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре | «Урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, җир кишәрлеге бирмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерык |
| 31 статья | Чәер әзерләү | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы боерык |
| $38^{1}$ статья | Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 13 октябрендәге 742 номерлы боерык |
| 39 статья | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерык |
| 34 статья | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | «Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы боерык |
| 40 статья | Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерык |
| 41 статья | Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (алга таба – Рослесхоз) норматив актлары** | | |
| 29 статьяның 6 өлеше | Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибе | «Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 27 маендагы 191 номерлы боерык<br>«Кисентеләрнең яшен билгеләү турында» 2015 елның 9 апрелендәге 105 номерлы боерык |
| 29 статьяның 7 өлеше, 81 статьяның 3 пункты | Агач материалы әзерләү. Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре | «Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 513 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | (токымнары) исемлеге | |
| 53 статьяның 4 өлеше, $53^1$ статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү | «Урманнарны янгынга каршы кору нормативларын раслау турында» 2012 елның 27 апрелендәге 174 номерлы боерык, «Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, һава торышына карап, урманнарда табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында» 2011 елның 5 июлендәге 287 номерлы боерык |
| 65 статьяның 5 өлеше | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкларын үстерү районнарын билгеләү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 1032 номерлы боерык |
| **Россия Федерациясе субъекты норматив актлары** | | |
| 82, 83 статьялар | Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре.<br>Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшыру | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-880 номерлы Указы,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 531 номерлы карары,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ яки муниципальара әһәмиятендәге гомуми файдалану автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2022 елның 13 октябрендәге 1099 номерлы карары |
| 82 статьяның 7 өлеше | Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү турында» 2020 елның 7 октябрендәге 107-2/нпс-2020 номерлы карары |

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылык һәм урнашкан урыны

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Бөгелмә урманчылыгы Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш өлешендә Азнакай, Ютазы, Лениногорск һәм Бөгелмә районнары территориясендә урнашкан.

Урманчылык конторасы (үзәк утары) Бөгелмә шәһәрендә, ул Бөгелмә тимер юл станциясеннән 3 километрда (алга таба – км) һәм республиканың башкаласы Казан шәһәреннән 350 км ераклыкта урнашкан.

Урманчылыкның почта адресы: 423250, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре, Парк урамы, 2а йорт.

Телефон: 8-(855)-949-65-00, E-mail: Bugulminskoe.Gku@tatar.ru.

### 1.1.2. Урманчылыкның, кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы, урманчылык территориясенең районнар буенча бүленеше

Урманчылык территориясенең муниципаль берәмлекләр буенча бүленеше 1 нче таблицада китерелә.

1 нче таблица

Урманчылыкның төзелеше

| Т/с | Урманчылык | Кишәрлек урманчылыклары | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | | 3 | 4 |
| 1. | Бөгелмә | Актүбә | Азнакай | 6089 |
| | | | Бөгелмә | 3430 |
| | | Җәмгысе | | 9519 |
| 2. | | Бөгелмә | Бөгелмә | 9679 |
| | | | Лениногорск | 246 |
| | | Җәмгысе | | 9925 |
| 3. | | Петровка | Бөгелмә | 9853 |
| | | Җәмгысе | | 9853 |
| 4. | | Ютазы | Ютазы | 8993 |
| | | | Баулы | 3636 |
| | | | Азнакай | 2078 |
| | | Җәмгысе | | 14707 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | | | **44004** |
| | | шул исәптән районнар буенча | | |
| 1 | | | Азнакай | 8167 |
| 2 | | | Бөгелмә | 22962 |
| 3 | | | Лениногорск | 246 |
| 4 | | | Ютазы | 8993 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | | | Баулы | 3636 |

Урманчылыкның урман фонды биләмәләр буларак та, аерым-аерым торучы, төрле зурлыктагы утраучыклар буларак та гыйбарәт. Территорияләрендә урман фонды урнашкан муниципаль районнарның урманлы өлеше 17,6 процент тәшкил итә.

Урманчылык территориясе бүлеп күрсәтелгән Татарстан Республикасы 1 нче схематик каратада күрсәтелгән.

1 нче карта-схема



### 1.1.3. Урман үсә торган зоналар, урманлы районнар һәм урманнарны саклау һәм урман-орлык районнарына бүлү зоналары буенча урманчылык урманнарын бүлү

Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы белән расланган урман үсү районнарына бүленеш нигезендә урманчылык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районына кертелгән (2 нче таблица).

2 нче таблица

Урманчылык урманнарын урман үсә торган зоналарга һәм урманлы районнарга бүлү

| Т/с | Кишәрлек урманчылык-лары | Урман үсә торган зона | Урманлы район | Урманнар-ны саклау районна-рына бүлү зонасы | Урман-орлык буенча районнарга бүленеш зонасы | Урман квартал-лары исемлеге | Мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Актүбә | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясе-нең Европа өлешендәге урман-дала районы | Урман авырулары буенча уртача хәтәрлек | Нарат өчен - 2, чыршы - 4, карагай - 3, имән - 2 | 1-98 | 9519 |
| 2. | Бөгелмә | | | | | 1-118 | 9925 |
| 3. | Петровка | | | | | 1-108 | 9853 |
| 4. | Ютазы | | | | | 1-221 | 14707 |
| барлыгы | | | | | | | 44004 |

Урманчылык территориясенең һәм кишәрлек урманчылыкларының урманнар үсә торган зоналарга һәм урманлы районнарга бүленеше 2 нче схематик картада күрсәтелгән.

2 нче карта-схема

**РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ**
**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# КАРТА-СХЕМА

**с распределением территории лесничества и участковых лесничеств по лесорастительным зонам и лесным районам**

## БУГУЛЬМИНСКОГО ЛЕСНИЧЕСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

| № | Участковое лесничество | Площадь, га |
|---|---|---|
| 1 | Актюбинское | 9519 |
| 2 | Бугульминское | 9925 |
| 3 | Петровское | 9853 |
| 4 | Ютазинское | 14707 |
| | Итого | 44004 |




**Административно-территориальная единица:**

| | |
|---|---|
| 1 | Азнакаевский район |
| 2 | Бугульминский район |
| 3 | Бавлинский район |
| 4 | Лениногорский район |
| 5 | Ютазинский район |

**Условные обозначения:**

- Граница лесничества
- Границы участковых лесничеств
- Граница Республики Татарстан
- Границы административно-территориальных единиц
- Границы административно-территориальных единиц
- Границы кварталов
- 1 Номера участковых лесничеств
- 1 Номера административно-территориальных единиц
- 10 Номера кварталов
- Автомобильные дороги
- Реки, озера, водохранилища
- Реки, ручьи
- Населенные пункты

**Лесорастительная зона и лесной район:**

Лесостепной район:
- Лесостепной район Европейской части Российской Федерации

**Масштаб 1 : 500 000**

## 1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм саклагыч урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук саклагыч, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре

3 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеше һәм саклык урман категорияләре буенча бүленеше

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйда-ны, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Барлыгы урманнар | | | 44004 | |
| 2. | 1. Саклык урманнары, барлыгы: | | | 40614 | |
| 3. | Шул исәптән: | | | | |
| 4. | 1.1. су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Барлыгы | | 1761 | РФ Урман кодексы, РФ Су кодексы, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы, Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Урманнарны тәртипкә китерү инструкциясен раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 510 номерлы боерыгы |
| | | Актүбә | Әлеге квартал өлешләре: 1-2, 4, 7-8, 10, 12-13, 16-18, 21-22, 26-28, 34-35, 37-39, 41, 50, 54-55, 58-61, 64-66, 70, 72-77, 82, 88, 90-95, 98 | 562 | |
| | | Бөгелмә | Әлеге квартал өлешләре: 1, 4-6, 10, 14, 16, 21, 30, 38, 40, 43, 45-47, 49-52, 59, 64, 66-67, 77, 83, 93, 101, 105, 107, 110, 112-113, 115, 118 | 289 | |
| | | Петровка | Әлеге квартал өлешләре: 9, 11-12, 19-20, 22, 27-28, 32, 36-40, 42, 44, 48, 55-56, 58-59, 61, 63-64, 67, 84-85, 88-91, 93, 99-101 | 327 | |
| | | Ютазы | Әлеге квартал өлешләре: 10-11, 13-16, 19, 24-30, 34-39, 41, 48, 50-51, 55-56, 66, 82, 87-89, 92, 95, 97, 111, 113, 123-125, 127, 137, 160, 168, 172, 193-199, 201, 204, 206-209, 211, 215-219, 221 | 583 | |
| 5. | 1.2. табигый һәм башка объектларны саклау вазыйфасын үтәүче урманнар, шул исәптән, барлыгы: | | | 6959 | |
| 6. | 1.2.1. | Барлыгы | | 2646 | РФ Урман кодексы, |

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйда-ны, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | саклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар | Актүбә | Әлеге квартал өлешләре: 1-2, 8-9, 15, 22, 26-27, 29, 31, 37, 39-40, 47, 51, 59-60, 65, 70, 72, 75-80, 82-84, 86-88, 90-94, 96-98 | 636 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман корылышы буенча файдалану күрсәтмәсен раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 510 номерлы боерыгы |
| | | Бөгелмә | Әлеге квартал өлешләре: 2-3, 5-10, 12, 19, 21-22, 23-28, 31-34, 35, 37, 41-42, 45-48, 53-56, 58, 60-62, 65, 67, 68-76, 78, 79-82, 84-86, 87-88, 89, 90-92, 94-96, 100-105, 107, 109-115, 118 | 1020 | |
| | | Петровка | Әлеге квартал өлешләре: 1-3, 8-10, 12-14, 17-19, 36, 45-47, 49-50, 52, 57-58, 80-82, 85, 87-88, 90, 94, 97, 103, 106, 108 | 424 | |
| | | Ютазы | Әлеге квартал өлешләре: 47, 56, 72, 76, 78, 96-97, 103, 106-107, 110-114, 116, 118-119, 123-124, 126, 131, 138, 140-141, 155, 157, 159-160, 165-168, 174-176, 201-208, 210-211, 213-214, 216, 218-219 | 566 | |
| 7. | 1.2.2. урман паркы зоналарында урнашкан урманнар | Барлыгы | | 4313 | |
| | | Бөгелмә | Әлеге квартал өлешләре: 23-28, 31-34, 53-56, 68-76, 79-82, 87-88, 90-92, 94-96 | 3626 | |
| | | Петровка | Әлеге квартал өлешләре: 45-47, 49-50, 52 | 687 | |
| 8. | 1.3. кыйммәтле урманнар, барлыгы: | | | 31894 | |
| 9. | Шул исәптән: | | | | |
| 10. | 1.3.1. урман-дала урманнары | Барлыгы | | 31727 | РФ Урман кодексы, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү |
| | | Актүбә | Кварталлар: 32-33, 42-46, 48-49, 52-53, 56-57, 67-69, 71, 81, 85, 89<br>Әлеге квартал өлешләре: 28, 34-35, 37-41, 47, 50-51, 54-55, 58, 65-66, 70, 72-80, 82-84, 86-88, 90-98 | 4922 | |

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйда-ны, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 44, 57, 99, 106, 108, 116-117<br>Әлеге квартал өлешләре: 1-22, 29-30, 35-43, 45-52, 58-67, 77-78, 83-86, 89, 93, 97-98, 100-105, 107, 109-115, 118 | 4885 | һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | | Петровка | Әлеге квартал өлешләре: 2-44, 37-39, 48, 51, 53-108 | 8362 | |
| | | Ютазы | Кварталлар: 117, 120-122, 128-130, 132-136, 139, 142-154, 156, 158, 161-164, 169-171, 173, 177-192, 200, 212, 220<br>Әлеге квартал өлешләре: 1-116, 118-119, 123-127, 131, 137-138, 140-141, 155, 157, 159-160, 165-168, 172, 174-176, 193-199, 201-211, 213-219, 221 | 13558 | |
| 11. | 1.3.2. фәнни яки тарихи-мәдәни әһәмияткә ия урманнар | Барлыгы | | 167 | |
| | | Актүбә | 37 квартал өлеше | 9 | |
| | | Бөгелмә | Әлеге квартал өлешләре: 18, 35-36 | 105 | |
| | | Петровка | Әлеге квартал өлешләре: 37-39 | 53 | |
| 12. | 2. Эксплуатация урманнары | барлыгы | | 3390 | РФ Урман кодексы, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | | Актүбә | Кварталлар: 3, 5-6, 11, 14, 19-20, 23-25, 30, 36, 62-63<br>Әлеге квартал өлешләре: 1-2, 4, 7-10, 12-13, 15-18, 21-22, 26-27, 29, 31, 59-61, 64 | 3390 | |

### 1.1.5. Урманчылык территориясендә урман фонды җирләре составыннан урманлы һәм урмансыз җирләргә сыйфатлама

4 нче таблица

Урманчылык территориясендә урман фондының урманлы һәм урмансыз җирләренә сыйфатлама

| Т/с | Җирләрнең категориясе | Урманчылык буенча барлыгы | |
|---|---|---|---|
| | | Мәйданы, га | % |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | 1. Урманнарның гомуми мәйданы | 44004 | 100,0 |
| 2. | 2. Урманлы җирләр, барлыгы | 41497 | 94,30 |
| 3. | 2.1.Урман үсемлекләре үсә торган җирләр, шул исәптән | 40452 | 91,93 |
| 4. | урман культуралары | 10650 | 24,20 |
| 5. | 2.2. Урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр, барлыгы, шул исәптән | 1045,0 | 2,37 |
| 6. | тоташмаган урман культуралары | 592 | 1,35 |
| 7. | питомниклар һәм урман плантацияләре | 17 | 0,04 |
| 8. | аралыклар | - | - |
| 9. | Көекләр | - | - |
| 10. | һәлак булган урман утыртмалары | 98 | 0,22 |
| 11. | киселгән урыннар | 129 | 0,29 |
| 12. | ачык, ташландык урыннар | 209 | 0,47 |
| 13. | 3. Урман булмаган җирләр, барлыгы, шул исәптән | 2507 | 5,70 |
| 14. | Сөрүлекләр | 79 | 0,18 |
| 15. | Печән чабу урыннары | 243 | 0,55 |
| 16. | җәйләүләр | 318 | 0,72 |
| 17. | сулар | 48 | 0,11 |
| 18. | бакчалар | 6 | 0,01 |
| 19. | юллар, ызаннар | 258 | 0,59 |
| 20. | утарлар һәм башка объектлар | 144 | 0,33 |
| 21. | Сазлар | 7 | 0,02 |
| 22. | комнар | - | - |
| 23. | башка төрле җирләр | 1404 | 3,19 |

### 1.1.6. Гамәлдәге һәм проектлана торган махсус саклана торган табигать территорияләренә һәм объектларга, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелеген саклау планнарына сыйфатлама

Хокукый режим РФ Урман кодексының 112 статьясыбелән билгеләнә. Бу җирләр әйләнештән алынган яки әйләнешендә чикләнгән (РФ Җир кодексының 27 статьясы).

Махсус саклана торган табигать территорияләрендә тыела яисә рөхсәт ителә, гамәлгә ашырыла торган конкрет эшчәнлек төрләре, шул исәптән урманнардан файдалану, аларны саклау яисә яңадан җитештерү өлкәсендә, РФ Җир кодексы, РФ Урман кодексы, «Махсус саклана торган табигать территорияләре

турында» 33-ФЗ номерлы федераль закон, шулай ук аларны үтәү өчен чыгарылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Урманчылык территориясендә гамәлдәге һәм проектлана торган түбәндәге махсус саклана торган табигать территорияләре (алга таба – МСТТ) бар.

Махсус сакланыла торган табигать территорияләре исемлеге

| Т/с | МСТТ | Мәйданы, га | Урнашкан урыны, кишәрлек урманчылыгы, квартал, бүлемтек | МСТТ профиле, бүлеп чыгару нигезе | Кыскача сыйфатлама һәм урман хуҗалыгы алып бару тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Төбәк әһәмиятендәге биологик (ботаник) профильле дәүләт табигать тыюлыгы | | | | | |
| 1 | Владимировка сөзәклеге (Актүбә биләмәсе) | 9,0 | Актүбә кишәрлеге, 37 квартал (бүл. 1-2) | Татарстан АССР Министрлар Советының 1991 елның 23 июлендәге 313 номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 644 номерлы карары | Ямаш елгасына төшә торган материк кыясы кишәрлеге. Язгы адонисның зур популяциясе булган, болын, дала үсемлекләре, шулай ук Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән бөҗәкләр сакланган төрле типчаклы кылган даласы өлешләре сакланып калган. Дару үләннәре резерваты буларак фәнни-гамәли әһәмияткә ия. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| 2 | Яңа Александровка сөзәклеге | 44,2 | Бөгелмә кишәрлеге урманчылыгы, 35 квартал (бүл. 11, 16-19, 22), 36 (бүл. 6, 13-15, 17, 18) һәм янәшәдәге территориядә | Татарстан АССР Министрлар Советының 1991 елның 23 июлендәге 313 номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 644 номерлы карары | Кишәрлек бер-бер торучы, якынча 70 еллык каеннардан һәм туфрак өсте катламында болын-дала үсемлекләреннән формалашкан сөзәк үзәнлектә урын алган. Үсемлекләр арасында гадәти һәм язгы адонис өстенлек итә, аларның тыгызлыгы мәйданның 1 квадрат метры өчен 2,5 үсемлек тәшкил итә. Дару үләннәре резерваты һәм аларны үстерү өчен орлык чәчү юлы белән аларны культуралаштыру урыны буларак фәнни-гамәли әһәмияткә ия. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| 3 | Адонис урманы | 61,0 | Бөгелмә кишәрлеге, 18 кв. (8, 13-17, 22-25 бүлемтекләр) | Татарстан АССР Министрлар Советының 1991 елның 23 июлендәге | Урман биләмәсеннән торган яссы платодан гыйбарәт, аның кисек катламы астында дала һәм урман үсемлекләре үсә. Мәйданы - 61 га. Кишәрлектә 150 якын үсемлек төре билгеләнгән, алар арасында ТР Кызыл китабына кертелгән төрләр дә бар (Трансильвания |

| Т/с | МСТТ | Мәйданы, га | Урнашкан урыны, кишәрлек урманчылыгы, квартал, бүлемтек | МСТТ профиле, бүлеп чыгару нигезе | Кыскача сыйфатлама һәм урман хуҗалыгы алып бару тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | 313 номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 644 номерлы карары | ярмабашы һ.б.). Кишәрлек үзендә үсә торган үсемлекләрнең дару төрләре резерваты (язгы адонис) буларак фәнни-гамәли әһәмияткә ия. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| Төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигать тыюлыгы | | | | | |
| 4 | Чатыр Тау | 1777,0 | Ютазы кишәрлеге урманчылыгы, кв.: 1-30 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 елның 24 июнендәге 390 номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 18 июлендәге 353 номерлы карары | Табигать тыюлыгы Сәпәй, Әсәй, Уразай һәм Чәкән торак пунктлары янында Бөгелмә-Бәләбәй материк платосында урнашкан 5 кишәрлектән тора. Тыюлык территориясе буйлап Ык, Стәрле, Вәрҗәде елгалары ага. Тыюлык территориясендә Чатыр Тау – Татарстан Республикасының иң югары нокталарыннан берсе урнашкан, аның биеклеге – диңгез дәрәҗәсеннән 321,7 м. Вәрҗәде елгасына карап торучы тауның текә ягыннан куәтле чишмә ага. Грунт сулары чыгу урыннарында тау итәгендә ике төп сазлык барлыкка килгән. Уйсулыкларда һәм тау кыялары буйлап имән-юкә, имән-каен һәм юкә-усак агачлары үсә, аларның куаклары арасында кабар агачы, урман чикләвеге, өрңәге һәм миләш үсә. Нарат һәм чыршы утыртмалары бар. Текә кыялар бөртекләр-кылган һәм төрле үлән-типчак даласы, тубылгы куагы, чия, миндаль үсемлекләре булган урыннарны алып тора. Бөҗәкләрдән турыканатлылар күп, ә коңгызлардан – кара коңгызлар, алар арасында иң зурысы да очрый: далаларда яши торган кара коңгызлар да очрый. Салихов тавында ТР өчен сирәк булган дала бөҗәкләре – суфи чикерткә һәм далада яши торган зур яшел чикерткә очрый. Кыялар буйлап даими рәвештә сикереп йөри торган кәлтәләр күзәтелә. Кошлардан еш кына йомран һәм байбак ояларыннан оялаган гади таш чыпчыгы, сары чәперчек кош, гади солы чыпчыгы, ә зур булмаган урманнарда кызылтүш һәм урман |

| Т/с | МСТТ | Мәйданы, га | Урнашкан урыны, кишәрлек урманчылыгы, квартал, бүлемтек | МСТТ профиле, бүлеп чыгару нигезе | Кыскача сыйфатлама һәм урман хуҗалыгы алып бару тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | тургае очрый. Урман кишәрлекләрендә җирән кыр тычканы, сары муенлы тычкан, урман тычканы, җир тычканы, ачык урыннарда кыр тычкны, гади җир тычканы, «экономка» җир тычканы яши. Тыюлык территориясендә иң зур үсүче йомран-байбакның колониясе урын алган. Тыюлык территориясенең 50 дала үсемлеге Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең кызыл китапларына кертелгән, алар арасында гади садә, зур чәчәкле тәңкәяфрак, төрле сабаклы дару кыяр үләне, известь ярата торган мәкә үсә. Бөҗәкләрдән Кызыл китапка кертелгән түбәндәге төрләр бар: спорадикус төклетурасы, йонеллюс төклетурасы, балтачы умарта корты, төклетурага охшаш мегахила, уракчы кырмыска, зур сусөяр, адмирал, зәңгәр тасмачы; сөйрәлүчеләрдән – гади кара елан, бакыр елан, җизбаш; кошлардан – каракош, торымтай, дербник, алтынсу корташар кош; имезүчеләрдән – слепушонка, Эверсман әрләне, соры әрлән, дала йомраны, биредә алар өчен арелның төньяк чиге уза. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле | | | | | |
| 5 | Петровка наратлыгы | 53,0 | Петровка кишәрлеге, кварталар: 37 (бүлемтек: 19, 27, 37), 38 (бүлемтек: 2, 10), 39 (бүлемтек: 13) | Татарстан АССР Министрлар Советының 1989 елның 24 апрелендәге 167 номерлы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 644 | Көньяк экспозициянең текә кыясында урнашкан урман биләмәсеннән гыйбарәт. Сирәкләнгән агачлыклар аерым торучы 100 елдан картрак булган матур наратлардан барлыкка килгән. Аларның чыбылдыгы астында, куәтле яктылык шартларында 50 артык дала һәм болын үсемлек төрләре үсә, алар арасында: тәбәнәк миндаль, сары мәтрүшкә яфраклы тубылгы куагы, әрмән эреме, рус күкчәчәге, себер гамбәр үләне, шарсыман суган һәм башкалары Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән. Фауна өйрәнелмәгән. Табигый экосистемалар белән бергә саклана торган һәйкәл территориясе XIX гасыр корылмалары булган борынгы паркка да керә, хәзерге вакытта ял базасы буларак кулланыла. |

| Т/с | МСТТ | Мәйданы, га | Урнашкан урыны, кишәрлек урманчылыгы, квартал, бүлемтек | МСТТ профиле, бүлеп чыгару нигезе | Кыскача сыйфатлама һәм урман хуҗалыгы алып бару тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | номерлы карары | Паркка күп кенә чишмәләре булган матур буа килеп тоташа. Эстетик һәм фәнни әһәмияткә ия. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимын үтәү. Тоташ кисүләр тыела. Һәлак булган һәм зарарланган агачларны кисү максатларында сайланма кисүләр рөхсәт ителә. |
| 6 | Коробков сөзәклеге | 1,0 | Петровка кишәрлеге урманчылыгы, кв.: 100 (бүлем.: 12) | ТР Министрлар Кабинетының 2016 елның 4 маендагы 281 номерлы карары | Табигать һәйкәле территориясе зур өлеше белән Бөгелмә муниципаль районының Петровка авыл җирлеге җирләрендә урнашкан, 60,1 гектар мәйданлы ташлы даладан гыйбарәт һәм Бөгелмә урманчылыгының Петровка кишәрлеге урманчылыгындагы 100 нче кварталның 12 нче бүлемтегенә карый торган 1 гектар урман фонды җирләрен дә үз эченә ала.<br>Тикшеренүләр нәтиҗәсендә кишәрлектә ТР Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең 21 төре (ике башаклы кызыл тамыр, түгәрәк суган, Идел буе мәче борчагы, Сарепта кылганы һ.б.), кошларның 2 төре (көйгәнәк һәм ягылбай), имезүчеләрнең 3 төре (ике төсле ярканат, дала тычканы һәм соры әрлән), бөҗәкләрнең 6 төре (аюкүбәләк, поликсена, сатир дриада күбәләге һ.б.), амфибияләрнең 1 төре (бакыр елан) очраган. |

### 1.1.7. Илкүләм мирас буенча проектлана торган урманнарга сыйфатлама

Татарстан Республикасы территориясендә сыйфатламалары буенча илкүләм мирас урманнарына кертү өчен тиешле урманнар юк.

### 1.1.8. Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек төрләрен һәм буфер зоналары зурлыклары исемлеге

Биологик күптөрлелекне саклау – урман хуҗалыгы эшчәнлеген алып баруда зарури шарт. Ул саклагыч урманнарда, махсус сакланучы урман кишәрлекләрендә генә түгел, ә диләнке эшләре гамәлгә ашырылганда да тәэмин ителергә тиеш.

Урман кишәрлекләрендә кисү эшләре уздырылганда тереклек итү тирәлеге шартлары шактый үзгәрә. Үсеш алуның үзгәргән шартларында, яңа шартларга хас булганча, бары тик урман биоценозлары гына яши ала, шуңа күрә тереклек тирәлеген тамырдан үзгәртә торган тоташ кисү барышында биотопларны (биоценоз биләгән киңлекләрнең абиотик факторлары буенча беришлеләренә карата) максималь саклау мөһим.

Үсемлекләрнең һәм хайваннарның урман төрләре тереклек итә торган шартлар төрлелеген саклау өчен диләнкеләрне аерып чыгарганда һәм таксацияләгәндә әһәмиятле биотоплар (әһәмиятле объектлар) – кисү эшләре кагылмый торган һәм биотөрлелекне саклау өчен әһәмиятле булган, зур булмаган җир кишәрлекләре аерып чыгарыла, ә диләнкеләр эшләнгәндә, – саклана.

Аларның булуы билгеле бер дәрәҗәдә табигый җимерелү нәтиҗәләрен имитацияләргә булыша, киселгән урыннарда урман тирәлеген сакларга һәм торгызырга ярдәм итә. Әлеге объектлар Россия Кызыл китабына һәм/яки төбәкләрдәге Кызыл китапларга кертелгән, сирәк очрый торган һәм нәзберек булган тереклек организмнары төрләренең потенциаль тереклек итү урыннары булып тора.

Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек объектларының һәм буфер зоналарының нормативлары һәм параметрлары 20 нче таблицада чагылдырылды.

20 нче таблица.

Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек объектларының һәм буфер зоналарының нормативлары һәм параметрлары

| Т/с | Биологик күптөрлелек объектлары | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналарының күләмнәре (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Даими һәм вакытлы су агымнары | Су агымының аерым ачык күренеп тора торган үзәне. Вакытлы су агымы даими рәвештә су басу эзләре буенча ачыкланырга мөмкин. Коры җәйдә су агымы кибәргә мөмкин | Әгәр нормативларда башкача билгеләнмәсә, даими су агымнары өчен киңлеге кимендә 50 м, вакытлы су агымнары үзәннәре буйлап кимендә 20 м буфер зоналары |

| Т/с | Биологик күптөрлелек объектлары | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналарының күләмнәре (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | билгеләнә. Буфер зонасы инде урман баскан тугайлык булырга тиеш түгел һәм су агымы үзәненнән башлап яисә урмансыз тугайлыктан башлап һәр ягыннан үлчәнә.<br>**Искәрмә:** буфер зонасына мәҗбүри рәвештә сөзәк таулар һәм тамыр токымнары чыккан урыннар кертелергә тиеш |
| 2. | Кизләүләр (чишмәләр), грунт сулары чыгу урыннары | Төптә кизләүләр аерылып торырга мөмкин, яисә су таудан агучы чишмә рәвешендә агып чыга. Чишмә карст бүрәнкәсеннән агып чыгарга мөмкин | Чишмәләр буйлап (алар чыккан урыннар тирәли) киңлеге кимендә 50 м буфер зоналары аерыла.<br>Дәвалану яисә савыктыру максатларында файдаланыла торган, шулай ук зиярәт кылу объекты булып хезмәт итүче (изгеләр чишмәсе) чишмәләр тирәли буфер зонасы киңәйтелергә мөмкин – аерым тәртиптә билгеләнә. |
| 3. | Сазланган уйсулыклар һәм вакыты-вакыты белән су баса торган урыннар | Әлеге кишәрлек артыгы белән дымланган: су өслеккә чыккан яисә аяк белән басканда бүселеп чыга. Объект чикләрендә – артык дымланган урман типларының туфрак катламы. Кырые буйлап, шулай ук объектлар чикләрендә агачлар юк яисә товарлык дәрәҗәсе аз булган агачлар гына үсә | Су баса торган кишәрлек кырые буйлап су өслектә тора яисә басканда чыга. Рельефта түбәнрәк урында, туфрак өсте капламы чигендә, чиге буйлап туфрак өсте катламы һәм агачлыклар сыйфатында. |
| 4. | Күлләрнең, сазларның һәм башка ачык урыннарның ярлары буйлап урман кашаклары, сазлыкларда зур булмаган утраулар | Ачык киңлекләрнең (күлләр, сазлар, болыннар) ярларында урман кашакларын аерып чыгару урман корылышы буенча саклагыч полоса билгеләнмәгән очракта башкарыла | Киңлеге кимендә 50 м урман кашагы күл суыннан алып яисә ачык башка урын киселешеннән башлап үлчәнә. Ләкин, әгәр күлдә утраучык яисә сазланган урын булса, буфер зонасын каты яр кырыеннан яисә сазлык яки ачык территория кырыеннан башлап үлчиләр. Шулай ук сазлык белән әйләндереп алынган зур булмаган (0,5 гектарга кадәр) утраулар да билгеләнә. **Искәрмә:** әгәр әлеге күл яисә сазлык хайваннарның сезонлы туплану һәм үрчү урыны, сирәк очрый торган һәм |

| Т/с | Биологик күптөрлелек объектлары | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналарының күләмнәре (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | нәзберек төрләрнең фактта тереклек итү урыны булып торса, ул очракта буфер зонасы киңәйтелергә тиеш |
| 5. | Чокырлар, су агымнарының тирән үзәнлекләре, башка төрле сөзәклекләр | Су агымнарының тирән кергән үзәнлекләре һәм чокырлар – тауның текәлеге 10° башланып киткәндә. Башка текә таулар (киртләчләр, текә ярлар) – тауның текәлеге кимендә 20° булган очракта | Нормативларда башкача билгеләнмәсә, сөзәк тау өсте һәм асты буйлап киңлеге кимендә 15-20 метрлы буфер зоналары билгеләнә. Сөзәк тауның үзе һәм буфер зонасы әһәмиятле объект булып тора. |
| 6. | Төп токымнарның, урман белән капланган калкулыкның шәрә урыннары, известьлы токым, ачык комлы кишәрлекләр, дюналар, таш чәчелгән урыннар | Куәте аз булган туфрак үсемлекләре белән капланган, төп токымнар шәрәләнә торган урыннар. Таш чәчелгән урыннар – төрле зурлыктагы һәм шомалыктагы ташлар җыелмасы. Тау битләрендә, тау киртләчләрендә, ярларда һәм алар янәшәсендә еш очрый. Ташлы һәм шәрәләнгән урыннар аз куәтле туфрак үсемлекләре белән капланырга мөмкин. Комлы дюналар өлешчә аз куәтле туфрак-үсемлек катламы белән ныгытылырга мөмкин | Объект кишәрлекнең төп токымнары шәрәләнгән чиге буйлап яисә таш чәчелгән урын чиге буйлап билгеләнә. Таш чәчелгән, төп токымнар шәрәләнгән урын, дюна комплексы кырыеннан киңлеге кимендә 20 метрлы буфер зонасы билгеләнә. |
| 7. | Аерым зур йомры ташлар һәм кантарлар | Лишайниклар һәм үсемлекләр белән капланган аерым зур йомры ташлар (2 куб.метрдан башлап) һәм кантарлар | Аерым зур йомры ташларны мәйданлы объектны билгеләмичә генә билгеләргә була, аларның тупланышы мәйданлы объект буларак билгеләнә |
| 8. | Карст элементлары | Известькатнашмалы токым ятмалары якын яткан урыннарда ярыклар, бүрәнкәләр, юкка чыга торган су агымнары һәм сулыклар, коры үзәнлекле сазлыклар. Калын известьташ катламының су белән юылган куышлыклары. Өслегендә уйсулыклар, җимерек, ярык урыннар күренә. Карст элементлары белән чишмәләр, кизләүле сазлыклар бәйле булырга мөмкин. Өслегендә шәрәләнгән известьташлар күренергә мөмкин | Объект тирәли уйсулык, куышлык кырыеннан киңлеге кимендә 20 метрлы буфер зонасы билгеләнә. |
| 9. | Ачык һәм ярымачык урыннар | Урман белән капланмаган кишәрлекләр: зур булмаган аланлыклар, сирәклекләр, болынлыклар һ.б. (шул исәптән сазлыкланган). Агачларның тулылыгы 0,4 ким. Запас гектарына 50 куб.метрдан кимрәк | Чиге буйлап агачлар арасында (тулылыгы һәм запасы ким булган кишәрлек) |
| 10. | Таркалу тәрәзәләре | Төрле токымга караган, төрле таркалу | Таркалу тәрәзәләрен табигый |

| Т/с | Биологик күптөрлелек объектлары | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналарының күләмнәре (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | чыбык-чабык һәм җил аударган агачлар-туфрак комплекслары белән тупланган. | стадияләрендәге аунаклар бар (диаметры 20 сантиметрдан (алга таба – см) башлана). Җил аударган агач-туфрак комплекслары (ВПК) – зур агачларның тамыр системасы һәм туфракның өске катламнары белән бергә аву нәтиҗәсе | яңару төркемнәре, шулай ук башка объектлар белән берлектә билгеләү максатка ярашлы була. Билгеләү эше объект чикләре буенча башкарыла |
| 11. | Коры-сары, биек түмәрләр, куышлы агачлар, берән-сәрән ятучы зур чыбык-чабыклар | Төрле токымнардан зур күләмле (диаметры 20 см башлана торган) коры-сары. Куышлы һәм тукран тукыган әзләре булган коры-сары аеруча кыйммәтле була. 2-5 м биеклегендәге һәм 20 см зуррак диаметрлы табигый эре түмәрләр. Куышлы агачлар. Төрле токымга караган, төрле таркалу стадияләрендәге чыбык-чабыклар (диаметры 20 см башлана) | Диләнке эшләгәндә куркыныч тудырмый торган коры-сарыны саклау максатка ярашлы була. Корыган һәм куышлы тере агачлар зарури сакланырга тиеш |
| 12. | Күп еллык агачлар һәм аларның чәчәклекләре, җыйнак биологик кыйммәтле урыннар | Берән-сәрән күп еллык агачлар, аларның чәчәклекләре һәм җыйнак биологик кыйммәтле кишәрлекләр | Күп еллык, янгынга каршы корытылган наратлар, карт усак, кара зирек, кәҗә талы аеруча кыйммәтле. Агачларның ябалдашы яхшы үсеш алган һәм җилгә каршы торырга сәләтле булырга тиеш. Күп еллык агачларның чәчәклекләре һәм җыйнак биологик кыйммәтле өлешләре составында агачларны саклау оптималь булып тора |
| 13. | Төбәк өчен сирәк токым агачлары | Киң яфраклы токымлы агачлар: имән, корычагач, карама, өрәңге, юкә. | Сирәк токым агачларының җыйнак төркемнәрен һәм шушы токымнарга караучы берән-сәрән агачларны үз эченә алган чәчәклекләр саклана. |
| 14. | Сирәк һәм терлек азыгы булган куаклыклар | Чикләвек куагы, артыш, миләш, гөлҗимеш, зелпе куаклары һ.б. | Сөйрәнмәләрдән башка саклана |
| 15. | Яңартылуның гамәлдәге төркемнәре | Киселгән урыннарда үсеш алырга мөмкин булган ышанычлы үренте төркемнәре. Дренажланган урыннарда агач чыбылдыгы тәрәзәләрендә яңартылу төркемнәре, эре аунак өемнәре тупланган урыннарда чыршы шытып чыккан | Үренте чәчәклекләре яңартылуның югары тыгызланган өлеше чикләре буенча билгеләнә |
| 16. | Сирәк очраучы һәм нәзберек үсемлекләрнең һәм | Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм/яисә региональ Кызыл китапка кертелгән сирәк очраучы һәм нәзберек | Төрләрнең биологиясе һәм экологик таләпләре нигезендә билгеләнә. Күпчелек сирәк |

| Т/с | Биологик күптөрлелек объектлары | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналарының күләмнәре (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | гөмбәләрнең тереклек итү урыннары | үсемлек һәм гөмбә төрләренең яңа ачыкланган даими тереклек итү урыннары. | төрләрне билгеләве авыр булганга күрә, сирәк төр һәм аларны саклау өчен зарури чикләр булу-булмавын тәгаенләштерү өчен биология белгеченә мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә. Әгәр бер нөсхә яисә затларның җыйнак төркеме ачыкланса, алар тирәли киңлеге кимендә 50 метрлы буфер зонасын билгеләргә кирәк |
| 17. | Куышлы агачлар | Берән-сәрән тере яки куышлы коры агачлар | Аерым агачлар яки агач төркемнәре рәвешендә җилгә каршы торучанлыкны, бөҗәк ашаучы кошларны күчерү урыннарын тәэмин итү өчен, шулай ук башка кыйммәтле объектлар составында саклана |
| 18. | Зур оялыклары булган агачлар | Зур оялыклары булган агачлар саклана, диаметрында 1 метрдан зуррак оялар, шулай ук эре оялар тупланган урыннар махсус кыйммәткә ия | 1 м һәм аннан зуррак диаметрлы оялар өчен буфер зонасының киңлеге - 500 м (елның теләсә кайсы вакытында), ә калган оялар өчен 100-300 м кимрәк булырга тиеш (кошларның күздә тотылган төренә карап). Буфер зонасының зурлыгы орнитолог белгеч тарафыннан тикшерү, ояның кемгә каравын һәм статусын билгеләү нәтиҗәләре буенча тәгаенләштерелергә мөмкин |
| 19. | Зур кырмыска оялары | 0.5 м биегрәк булган кырмыска оялары | 0.5 м биегрәк булган кырмыска оялары тирәли 20 м радиуста кисүләр тыелган буфер зонасы аерып чыгарыла |

### 1.1.9. Гамәлдәге урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларына, урман инфраструктурасы ясауга бәйле булмаган объектларга, әлеге объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү чараларына территориаль планлаштыру документларында каралган сыйфатлама

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яклый торган урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге 1283-р номерлы боерыгы.

РФ Урман кодексының 13 статьясы нигезендә урман юллары урманнардан теләсә нинди файдалану ысулында, шулай ук урманнарны саклау һәм яңадан үрчетү максатларында да төзелергә мөмкин.

Гамәлдәге урман юлларына сыйфатлама киләсе таблицада китерелде.

Урман юлларына сыйфатлама

| Т/с | Юлларның төрләре | Юллар озынлыгы, км | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлы-гы | Урман хуҗалыгы (типлары буенча) | | | | Гомуми |
| | | | I тип | II тип | III тип | Җәмгысе | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Юллар, барлыгы | 257 | 7 | 151 | 6 | 164 | 93 |
| 2. | шул исәптән | | | | | | |
| 3. | а) автомобиль | 257 | 7 | 151 | 6 | 164 | 93 |
| 4. | алардан: | | | | | | |
| 5. | каты түшәмәле | 40 | 1 | - | - | 1 | 39 |
| 6. | грунт | 217 | 6 | 151 | 6 | 163 | 54 |
| 7. | шул исәптән | | | | | | |
| 8. | ел әйләнәсе кулланыла торган | 13 | - | 2 | - | - | 11 |

Урманчылык территориясендә булган гомуми файдаланудагы барлык автомобиль юллары һәм урман хуҗалыгы юллары агач материалы саты һәм эшкәртү урыннарына чыгару юллары булып хезмәт итә.

Квартал юлларының озынлыгы – 358 км. Урман юлларының гомуми озынлыгы – 257 км.

Гамәлдәге урман инфраструктурасы объектлары 95 км озынлыгында квартал ызаннары белән җирдән катнаш файдаланучылар белән берлектәге чикләрне чистартуны һәм 500 данә күләмендә – квартал баганаларын урнаштыруны таләп итә.

Урман эшкәртү инфраструктурасы (әзерләнгән агач материалын эшкәртү объектлары, биоэнергетика объектлары һәм башкалар) агач материалы белән башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен төзелә. РФ Урман кодексының 14 статьясына ярашлы рәвештә, саклагыч урманнарда, шулай ук РФ Урман кодексында, башка федераль законнарда каралган башка очракларда урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру һәм эксплуатацияләү тыела.

Урманчылык территориясендә урман эшкәртү объектлары юк.

Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урман фонды җирләрендә РФ Урман кодексының 21 һәм 21.1 статьяларына ярашлы рәвештә башкарыла.

Урманчылык территориясендә урман инфраструктурасын төзүгә бәйле булмаган чираттагы объектлар бар:

ясалма катламлы автомобиль юллары – 40 км;

электртапшыру линияләре – 6 км;

газүткәргечләр – 3 км;

нефтьүткәргечләр – 5 км;

бүтән трассалар – 10 км.

Линияле объектларның гомуми озынлыгы 64 км тәшкил итә.

Моннан тыш, 3 гектар мәйданда юлларны ремонтлау өчен табигый карьерлар бар.

Территориаль планлаштыру схемасы буенча урманчылык территориясендә өстәмә объектлар планлаштырылмый. Башка категориягә караган, урман урнашкан җирләрдә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү урманнарның максатчан билгеләнеше буенча башка федераль законнарда каралган очракларда рөхсәт ителә.

Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки эксплуатацияләү өчен кулланылган җирләр РФ Урман кодексының 21 статьясының 9 өлеше нигезендә рекультивацияләнергә тиеш.

Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм эчтәлегенә, аны әзерләү тәртибенә таләпләрне раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, шулай ук РФ Урман кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очрак-ларда, агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын саклагыч урманнарда урнаштыру тыела.

Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча, гамәлдәге һәм проектлана торган махсус саклanучы табигать территорияләрен, урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын, урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларны тамгалап, кварталлар буйлап бүлгәләнеше 3 номерлы карта-схемада күрсәтелде.

3 нче карта-схема

**РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ**
**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# КАРТА-СХЕМА

**подразделения лесов по категориям защитности, расположения особо охраняемых природных территорий, объектов лесной, лесоперерабатывающей инфраструктуры, объектов, не связанных с созданием лесной инфраструктуры**

## БУГУЛЬМИНСКОГО ЛЕСНИЧЕСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

| № | Участковое лесничество | Площадь, га |
|---|---|---|
| 1 | Актюбинское | 9519 |
| 2 | Бугульминское | 9925 |
| 3 | Петровское | 9853 |
| 4 | Ютазинское | 14707 |
| | Итого | 44004 |






**Условные обозначения:**

- Границы ООПТ
- Граница лесничества
- Границы участковых лесничеств
- Граница Республики Татарстан
- Границы административно-территориальных единиц
- Границы административно-территориальных единиц
- Границы кварталов
- Номера ООПТ
- Номера участковых лесничеств
- Номера административно-территориальных единиц
- 10 Номера кварталов
- Автомобильные дороги
- Реки, озера, водохранилища
- Реки, ручьи
- Населенные пункты

**Категория защитности:**

- Леса, расположенные в водоохранных зонах
- Леса, расположенные в защитных полосах лесов
- Леса, расположенные в лесопарковых зонах
- Лесостепные леса
- Леса, имеющие научное или историко-культурное значение
- Эксплуатационные леса

**Административно-территориальная единица:**

| | |
|---|---|
| 1 | Азнакаевский район |
| 2 | Бугульминский район |
| 3 | Бавлинский район |
| 4 | Лениногорский район |
| 5 | Ютазинский район |

**Особо охраняемые природные территории:**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Государственный природный Заказник регионального значения биологического (ботанического) профиля "Владимирский склон" | 1 |
| 2 | Государственный природный Заказник регионального значения биологического (ботанического) профиля "Адонисовый лес" | 3 |
| 3 | Государственный природный Заказник регионального значения биологического (ботанического) профиля "Ново-Александровский склон" | 2 |
| 4 | Памятник природы регионального значения "Петровские сосны" | 5 |
| 5 | Памятник природы регионального значения "Урочище Липовка" | 6 |
| 6 | Государственный природный заказник регионального значения комплексного профиля "Чатыртау" | 4 |

**Масштаб 1 : 500 000**

## 1.2. Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре

Урман мөнәсәбәтләрендә Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр, гражданнар һәм юридик затлар катнаша (РФ Урман кодексының 4 статьясы).

Шул ук вакытта, РФ Урман кодексының 5 статьясы нигезендә, урман динамикалы рәвештә яңартыла һәм трансформациягә бирелә торган табигый ресурс буларак карала, чөнки югарыда аталган статья нигезендә урманнардан файдалану, аларны саклау һәм яңадан үрчетү экологик система яки табигый ресурс кебек урман төшенчәсеннән чыгып гамәлгә ашырыла.

Урманчылык территориясендә урманнардан кварталларга бүлеп рөхсәтле файдалану төрләре 5 нче таблицада күрсәтелә.

5 нче таблица

Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйда-ны, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Агач әзерләү (РФ Урман кодексының 25, 29 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 2. | Терлек азыгы әзерләү (РФ Урман кодексының 25, 31 статьялары) | Биектау | - | - |
| | | Иске Казан | - | - |
| | | Матюшино | - | - |
| | | Столбище | - | - |
| | | барлыгы | | - |
| 3. | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю (РФ Урман кодексының 25, 32 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 4. | Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю (РФ Урман кодексының 25, 35 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 5. | Ау хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру (РФ Урман кодексының 25, 36 статьялары) Тыелган: урман-парк зоналарында урнашкан урманнар, шәһәр урманнары; яшел зоналарда урнашкан | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-22, 29-30, 35-52, 57-67, 77-78, 83-86, 86, 93, 97-118<br>Әлеге квартал өлешләре: 23-28, 31-34, 53-56, 68-76, 79-82, 87-88, 90-92, 94-96 | 6299 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-44, 48, 51, 53-108<br>Әлеге квартал өлешләре: 45-47, 49-50, 52 | 9166 |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйда-ны, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | урманнар, әгәр урман утыртмаларын кисүгә яки аучылык инфраструктурасы объектларын булдыруга китерсә | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 39691 |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару (РФ Урман кодексының 25, 38 статьялары). Тыелган: урман-парк зоналарында урнашкан урманнар, шәһәр урманнары; Тыюлыклы урман кишәрлекләре; МСК – печән чабу, умартачылык һәм товар аквакультурасы (товарлы балыкчылык) белән беррәттән тыелган; яшел зоналарда урнашкан урманнарда – печәнлекләрдән һәм умартачылыктан тыш, шулай ук печәнлекләр һәм умартачылык максатларында киртәләр торгызу тыела | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-22, 29-30, 35-52, 57-67, 77-78, 83-86, 86, 93, 97-118<br>Әлеге квартал өлешләре: 23-28, 31-34, 53-56, 68-76, 79-82, 87-88, 90-92, 94-96 | 6299 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-44, 48, 51, 53-108<br>Әлеге квартал өлешләре: 45-47, 49-50, 52 | 9166 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 39691 |
| 7. | Балык тотуны гамәлгә ашыру, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш (РФ Урман кодексының 25, 38.1 статьялары). | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 8. | Фәнни-тикшеренү, мәгариф эшчәнлегеен гамәлгә ашыру (РФ Урман кодексының 25, 40 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 9. | Рекреация эшчәнлегеен гамәлгә ашыру (РФ Урман кодексының 25, 41 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 10. | Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 42 статьялары). Тыела: су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Актүбә | Кварталлар: 3, 5, 9, 11, 14, 19-20, 23-25, 29-33, 36, 40, 42-49, 51-53, 56-57, 62-63, 67-69, 71, 78-81, 83-87, 89, 96-97<br>Әлеге квартал өлешләре: 1-2, 4, 7-8, 10, 12-13, 16-18, 21-22, 26-28, 34-35, 37-39, 41, 50, 54-55, 58-61, 64-66, 70, 72-77, 82, 88, 90-95, 98 | 8957 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 2-3, 7-9, 11-13, 15, 17-20, 22-29, 31-37, 39, 41-42, 44, 48, 53-58, 60-63, 65, 68-76, 78-82, 84-92, 94-100, 102-104, 106, 108-109, 111, 114, 116-117<br>Әлеге квартал өлешләре: 1, 4-6, 10, 14, 16, 21, 30, 38, 40, 43, 45-47, 49-52, 59, 64, 66-67, 77, 83, 93, 101, 105, 107, 110, 112-113, 115, 118 | 9636 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-8, 10, 13-18, 21, 23-26, 29-31, 33-35, 41, 43, 45-47, 49-54, 57, 60, 62, 65-66, 68-83, 86-87, 92, 94-98, 102-108<br>Әлеге квартал өлешләре: 9, 11-12, 19-20, 22, 27-28, 32, 36-40, 42, 44, 48, 55-56, 58-59, 61, 63-64, 67, 84-85, 88-91, 93, 99-101 | 9526 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-9, 12, 17-18, 21-23, 31-33, 40, 42-47, 49, 52-54, 57-65, 67-81, 83-86, 90-91, 93-94, 96, 98-110, 112, 114-122, 126, 128-136, 138-159, 161-167, 169-171, 173-192, 200, 202-203, 205, 210, 212-214, 220<br>Әлеге квартал өлешләре: 10-11, 13-16, 19, 24-30, 34-39, 41, 48, 50-51, 55-56, 66, 82, 87-89, 92, 95, 97, 111, 113, 123-125, 127, 137, 160, 168, 172, 193-199, 201, 204, 206-209, 211, 215-219, 221 | 14124 |
| | | барлыгы | | 42243 |
| 11. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү (РФ Урман кодексының 25, 39 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 12. | Урман питомниклары булдыру һәм аларны эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 39.1 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйда-ны, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 13. | Җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм табу (РФ Урман кодексының 25, 43 статьялары). Тыела: урман парклы зоналарында, яшел зоналарда урнашкан урманнар, шәһәр урманнары, урман парклы зоналарында җир асты геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру рөхсәт ителә | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-22, 29-30, 35-52, 57-67, 77-78, 83-86, 86, 93, 97-118<br>Әлеге квартал өлешләре: 23-28, 31-34, 53-56, 68-76, 79-82, 87-88, 90-92, 94-96 | 6299 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-44, 48, 51, 53-108<br>Әлеге квартал өлешләре: 45-47, 49-50, 52 | 9166 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 39691 |
| 14. | Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын төзү һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 44 статьялары) | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 15. | Линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 45 статьялары) Гамәлдәге линияле объектлар, шул исәптән, РФ Урман кодексында әлеге куллану төре буенча чикләүләр кертелгән яклагыч урманнар категориясендә дә, кулланылырга мөмкин | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 16. | Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 46 статьялары). Тыела: саклык урманнары, махсус сакланыла торган кишәрлекләр | Актүбә | - | - |
| | | Бөгелмә | - | - |
| | | Петровка | - | - |
| | | Ютазы | - | - |
| | | барлыгы | | - |
| 17. | Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру (РФ Урман | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | кодексының 25, 47 статьялары) | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |
| 18. | РФ Урман кодексының 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр | Актүбә | Кварталлар: 1-98 | 9519 |
| | | Бөгелмә | Кварталлар: 1-118 | 9925 |
| | | Петровка | Кварталлар: 1-108 | 9853 |
| | | Ютазы | Кварталлар: 1-221 | 14707 |
| | | барлыгы | | 44004 |

# 2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ЧОРЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮРЧЕТҮ НОРМАТИВЛАРЫ

## 2.1. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан агач материалы әзерләү өчен файдалану РФ Урман кодексының 29, 29.1, 30 статьялары, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалын әзерләү кагыйдәләрен һәм агач материалын әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерыгы белән расланган Агач материалын әзерләү кагыйдәләре белән регламентлана.

Агач материалы әзерләү эшкуарлык эшчәнлеге максатларында гражданнар, юридик затлар тарафыннан, шулай ук гражданнар тарафыннан – шәхси максатларда (җылыту, төзелмәләр торгызу һ.б. өчен) гамәлгә ашырылырга мөмкин.

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган искәрмәле очракларда урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач материалы әзерләүне гамәлгә ашыру рөхсәт ителә.

Чикләрендә агач материалы әзерләү өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителгән кварталлар исемлеге 5 нче таблицада күрсәтелә.

Әгәр РФ Урман кодексында башкасы билгеләнмәгән булса, диләнкедә (кисү өчен билгеләнгән урман утыртмалары урнашкан территориядә) агач материалын әзерләү өчен кисүләрне гамәлгә ашыру рөхсәт ителә (РФ Урман кодексының 23.1 статьясы):

1) өлгергән, картайган урман утыртмаларын;

2) урманнарны саклау буенча чаралар үткәргәндә уртача яшьтәге, өлгергән, картайган урман утыртмалары;

3) РФ Урман кодексының 13, 14, 21 һәм 21.1 статьяларында каралган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен, РФ Урман кодексының 68.3 статьясында каралган эшләрне башкару өчен билгеләнгән теләсә кайсы яшьтәге урман утыртмалары.

Агач материалы әзерләү эше эксплуатация урманнарында, саклагыч урманнарда гамәлгә ашырыла, әгәр РФ Урман кодексында, бүтән федераль законнарда башкасы каралмаса.

Саклагыч урманнарда тоташ кисүләр РФ Урман кодексның 21 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда һәм сайланма кисүләр үзләренең тирәлек хасил итә, су саклый торган, санитар-гигиеник, савыктыру һәм башка төрле функцияләрен югалта башлаган урман утыртмаларын саклагыч урманнарның максатчан билгеләнешен һәм алар башкара торган файдалы функцияләрнең сакланышын тәэмин итә торган урман утыртмаларына алмаштыруны тәэмин итмәгән очракларда гамәлгә ашырыла, әгәр РФ Урман кодексында башкача билгеләнмәгән булса.

Урман агачларын кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, әзерләнгән агач материалын алып чыгу агач материалы әзерләү максатларында урман кишәрлегеннән файдаланучы зат тарафыннан урман декларациясе буенча декларацияләнә торган чор башланган датадан 12 ай эчендә гамәлгә ашырыла. Агач материалы урман агачларын сату-алу шартнамәсе яисә РФ Урман кодексының 19 статьясының 5 өлешендә күрсәтелгән контракт нигезендә әзерләнгән очракта, агачларны кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, алып чыгу эшләре шартнамәдә яисә контрактта билгеләнгән вакыт эчендә тиешенчә гамәлгә ашырыла.

Урман агачларын, тарттыруның (транспорт белән күчерүнең), өлешчә эшкәртүнең, саклауның, алып чыгуның вакытлары урманнан файдаланучы затның язмача гаризасы нигезендә, вәкаләтле орган тарафыннан иң күбе 12 айга арттырылырга мөмкин.

